| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 г.Зеленодольск № 263

«Зеленодольск шәһәре территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 9 июлендәге 196 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 217 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 11, 12, 13 пунктлары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына «Зеленодольск шәһәре» территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы (2018 елның 9 июлендәге 196 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 217 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 2 пунктчасының икенче абзацында «, бирелгән» сүзен һәм
«, дача» сүзен төшереп калдырырга;

2) 3 пунктның җиденче абзацында «, бирелгән» сүзен һәм «дача» сүзен төшереп калдырырга;

3) 3 пунктның сигезенче, тугызынчы һәм унынчы абзацларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым

түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирү турында гариза тапшыру, салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау, мондый гаризаның салым органы тарафыннан карау, салым түләүчегә салым ташламасы бирү турында хәбәрнамә җибәрү йә салым ташламасы бирүдән баш тарту турында хәбәр җибәрү Россия Федерациясе Салым кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Салым ташламасы бирү турында гариза формасы һәм аны тутыру тәртибе, мондый гаризаны электрон формада тапшыру форматы, салым ташламасы бирү турында хәбәр итү формалары, салым ташламалары бирүдән баш тарту турындагы хәбәрләр салым һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.».

2. Әлеге карарның гамәли көче 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда», газетасында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Карар салым законнары нигезендә үз көченә керә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры урынбасары** **К.С. Антипов**